МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

№__259/о____

П Р И К А З | Б О Е Р Ы К

«__13__»_____03_______2025___

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы белән расланган Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 01.12.2022 ел, №176/о, 09.02.2023 ел, №20/о, 28.12.2023 ел, №219/о, 14.06.2024 ел, №161/о боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Юридик бүлеккә (Р.И.Кузьминга), дәүләт теркәвенә алу өчен, әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторына (Р.Җ. Зәйнуллинага) әлеге боерыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның гамәлдә булуын 2025 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр вазыйфаларын башкаручы Д.Ф.Шәйдуллин

Отдел контроля исполнения документов

Татарстан Республикасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының
13.03.2025 ел, №_259/о
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 27 июнендәге 69/о номерлы боерыгы белән расланган Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

2.6.1 пунктта:

«в» пунктчасында «гамәлгә ашырган өчен дәүләт пошлинасын» сүзләреннән соң «дәүләт кадастр исәбен һәм (яисә)» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле унтугызынчы абзац өстәргә:

«2.6.1 пункт нигезләмәләре төзүченең һәм (яисә) башка затның (башка затларның) реконструкцияләнгән бинага, корылмага һәм (яисә) мондый бинада, корылмада урнашкан урыннарга, машина урыннарына дәүләт теркәвен гамәлгә ашыруга ризалыгы өлешендә һәм мондый теркәүне гамәлгә ашыру өлешендә аларның милек хокукы бинаны, корылмаларны реконструкцияләү нәтиҗәсендә мондый бинада, корылмада яңа биналар яисә элек исәпкә алынган һәм (яисә) машина урыннары төзелгән очракларда гына кулланыла. Әлеге абзацта күрсәтелмәгән очракларда, капиталь төзелеш объектын эксплуатациягә кертүгә рөхсәт һәм «Күчемсез мөлкәтне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге
218-ФЗ номерлы федераль законда каралган башка документлар нигезендә күрсәтелгән федераль законның 40 статьясындагы 6 өлешендә каралган тәртиптә бинаның, корылманың реконструкция нәтиҗәсендә характеристикалары үзгәрүгә, шулай ук мондый бинадагы, корылмадагы урыннарның, машина урыннарының характеристикалары үзгәрүгә бәйле рәвештә дәүләт кадастр исәбенә алу гамәлгә ашырыла.»;

2.8.2 пунктта:

3) пунктчада «капиталь төзелеш объекты мәйданы үзгәргән» сүзләреннән соң «, линия объектының озынлыгы» сүзләрен өстәргә;

4) пунктчада «капиталь төзелеш объекты мәйданы үзгәрү» сүзләреннән соң «, линия объектының озынлыгы» сүзләрен өстәргә.